СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 19 октябре № 24/32/4-2022

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 17/27/4-2022 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 17/27/4-2022 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны төшереп калдырырга;

б) 17 статьяның 1 өлешенең 1 пунктында «шәһәр» сүзен «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) 17 статьяның 1 өлешенең 10 пунктында «ел саен хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш» сүзләрен «тапшырырга» сүзенә алмаштырырга;

г) 17 статьяның 2 өлешендә «шәһәр» сүзен «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 йорт; Бәкер авылы, Нагорная урамы, 38 йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе А.А.Вәлиәхмәтов